ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЗАКЛАР ЧАЛЛЫСЫ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**КАРАР № 6**

24 нче сентябрь 2024 ел Казак Чвллысы авылы

Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 210-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге “Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында” 175 номерлы карарына, шулай ук Башкарма комитетның 2022 елның 11 февралендәге 28пи номерлы “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында”гы карарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Казак Чаллысы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең кушымта итеп бирелә торган административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитетының “Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2022 елның 30 мартындагы 5 номерлы карарын;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 нче елның 30 мартындагы 5 номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында" 2022 нче елның 22 нче ноябрендәге 17 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Казаклар Чаллысы авылы, Иванов урамы, 26 нчы йорт; Иванаево авылы, Калинин урамы,18 йорт; Бирдебәк авылы, Мәктәп урамы, 5 йорт;Үри Чаллысы авылы, Гаврилов урамы, 24 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Казак Чаллысыавыл җирлеге Башлыгы Ф.Х.Хәсәншин